РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» декабрь 2019 ел г. Альметьевск № 2279

«Физик культура һәм спорт буенча спорт чараларын, укыту-тренировка җыеннарын һәм башка чараларны үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2011елның 06 апрелендәге 1352 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чаралары календарь планына кертелгән физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм күнегүләр чараларын үткәрүгә чыгымнар нормативларын раслау турында» 2015 елның 18 мартындагы 160 нчы карары, «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чаралары календарь планына кертелгән физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм күнегүләр чараларын үткәрүгә чыгымнар нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 18 мартындагы 160 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 21 сентябрендәге 868 номерлы карары нигезендә, муниципаль физкультура һәм спорт-масса чараларын уздыруга бюджет акчаларын рациональ һәм нәтиҗәле файдалану, республика, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда Әлмәт муниципаль районы спортчыларын һәм җыелма командаларын уңышлы әзерләү һәм аларның чыгышларын нәтиҗәле файдалану максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. «Физик культура һәм спорт буенча спорт чараларын, укыту-тренировка җыеннарын һәм башка чараларны үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2011елның 06 апрелендәге 1352 номерлы карарына үзгәрешләр (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 29 июлендәге 2158 номерлы, 2015 елның 5 июлендәге 644 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үзгәрешләр кертергә:

Зак. № 305-2000

карарның 1 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм укыту-тренировка (күнегүләр) чараларын үткәргәндә спортчыларны, тренерларны һәм белгечләрне тукландыруны тәэмин итү чыгымнары нормалары»

| № п/п | Спорт чаралары исеме | Көнгә бер кешегә чыгымнар нормасы (сумнарда) |
|---|---|---|
| | | туклану |
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Массакүләм физкультура-спорт ярышлары һәм чаралар | 365 кадәр |
| 2 | Татарстан Республикасы чемпионатлары, беренчелекләре, кубоклары һәм аларга өйрәнү-тренировка (күнегүләр) чаралары (спартакиадалар, Универсиада), чит шәһәрләрдән килгән спортчыларны чакырып, ачык турнирлар: | 365 кадәр<br>425 кадәр |
| 3 | - Әлмәт муниципаль районы һәм Әлмәт шәһәре территориясендә | 730 кадәр |
| 4 | - Әлмәт муниципаль районыннан читтә | 785 кадәр |
| 5 | Бөтенроссия ярышлары һәм укыту-тренировка җыеннары | 850 кадәр |

искәрмә:

1. 90 кг нан артык авырлыктагы һәм/яисә зуррак булган спортчыларга әлеге кушымтада билгеләнгән нормаларның аерым очракларында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә 50 процентка кадәр күтәрелергә мөмкин.

2. Спорт чаралары үткәрү урыннарында оешкан тукклануны акчасыз исәп-хисап буенча тәэмин итү мөмкинлекләре булмаганда, спорт чараларында катнашучыларга әлеге кушымтада китерелгән чыгымнар нормалары чикләрендә кулдан акча бирү рөхсәт ителә»;

Карарга 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Спорт судьяларына спорт чараларын күрсәткән өчен түләү чыгымнары нормативлары»

| № п/п | Судья вазыйфаларының исеме | Судья категорияләрен исәпкә алып түләү күләмнәре (сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | МК, ВК | 1К | 2К | 3К/Ю/С | категориясез |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1 | Баш судья | 745 | 630 | - | - | - |
| 2 | Юаш судья-секретарь | 745 | 630 | - | - | - |
| 3 | Баш судья урынбасары, баш секретарь | 685 | 570 | 455 | - | - |
| 4 | Судья | 640 | 510 | 435 | 400 | 350 |
| Команда һәм уен спорт төрләре | | | | | | |
| 5 | Уенның Баш судьясы | 435 | 400 | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Уенның Баш судьясы ярдәмчесе | 365 | 340 | - | - | - |
| 7 | Инспектор (техник делегат, комиссар) | 435 | - | - | - | - |
| 8 | Судьиялар (бригада составында) | 330 | 310 | 285 | 260 | 230 |

Шартлы билгеләнешләр:
МК-халыкара категорияле спорт судьясы;
ВК-Бөтенроссия категорияле спорт судьясы;
1К-беренче категорияле спорт судьясы;
2К-икенче категорияле спорт судьясы;
3К-өченче категорияле спорт судьясы;
Ю/С-яшь спорт судьясы.

искәрмә:

1. Түләү күләме, спортның команда уен төрләреннән тыш, бер уенга (футбол, алкалы хоккей, баскетбол, волейбол, су полосы, гандбол, туплы хоккей, чирәмдәге хоккей, бейсбол, регби һ. б.) хезмәт күрсәтү өчен каралган.

2. Ярышларның әзерлек һәм йомгаклау этапларында баш судьяның, баш судья-секретарьнең эше өчен түләү өстәмә рәвештә 2 көнгә, баш судья урынбасарына һәм баш судья - секретарьның урынбасарына 2 көнгә арта.

3. Суд коллегиясенең (бригадаларның) саны спорт төрләре буенча ярышлар уздыру турында расланган кагыйдәләр нигезендә билгеләнә.

4. Халыкара, бөтенроссия ярышларын, Татарстан Республикасы чемпионатларын һәм кубокларын оештыру һәм үткәрү буенча контрольне гамәлгә ашыру өчен уеннарның баш судьялары өчен каралган күләмнәрдә түләүле инспекторлар яисә техник делегатлар билгеләнергә мөмкин»;

карарга 4 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Спорт чараларын уздырганда истәлекле призлар һәм акчалата бүләкләүләр сатып алуга чыгымнар нормативлары»

| № п/п | Спорт чаралары исеме | Истәлекле бүләкләр һәм акчалата бүләкләр бәясе (сумнарда) | |
|---|---|---|---|
| | | команда ярышлары | шәхси ярышлар |
| 1. | Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә торган халыкара ярышлар<br>I урын<br>II урын<br>III урын | <br><br>2 000 кадәр<br>1 800 кадәр<br>1 600 кадәр | <br><br>1 500 кадәр<br>1 300 кадәр<br>1 100 кадәр |
| 2. | Чемпионатлар, Россия беренчелекләре һәм кубоклары, шулай ук массакүләм физкультура-спорт чаралары финалы:<br>I урын<br>II урын<br>III урын | <br><br><br>1 500 кадәр<br>1 300 кадәр<br>1 100 кадәр | <br><br><br>1 200 кадәр<br>1 000 кадәр<br>800 кадәр |

искәрмә:

1. Акчалата бүләк бирү, истәлекле бүләкләрнең эквивалент бәясен бирү тыела.

2. Спортның команда төрләрендә һәм команда дисциплиналарында призлы урыннар алган командалар кубоклар, ә командалар - медальләр һәм дипломнар белән бүләкләнәләр.

3. Чыгыш йомгаклары буенча Әлмәт муниципаль районы кубокларында яисә I урынны алган командаларга кубок, медаль һәм диплом, ә II һәм III урыннар призерларына медальләр һәм дипломнар бирелә.

4. Җиңүче спортчыларның һәм призерларның (командаларның) тренерлары Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Физик культура, спорт һәм туризм идарәсенең дипломнары (грамоталары) белән бүләкләнә.

5. Күрсәтелгән нормативлардан югарырак спорт чараларын уздырганда истәлекле призлар алган очракта, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең аерым карарлары белән раслана»;

карарның 8 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Физик культура һәм спорт-массакүләм чараларга хезмәт күрсәткән өчен административ-хуҗалык һәм хезмәт күрсәтүче персоналга түләү чыгымнары нормалары»

| № п/п | Вазыйфаларның исеме | Көнгә түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1. | Җыю башлыгы (администратор) | 217 |
| 2. | Комендант | 193 |
| 3. | Дистанция һәм трассалар башлыгы | 217 |
| 4. | Дистанция һәм трассалар башлыгы урынбасары | 205 |
| 5. | Спортның җәйге төрләре буенча контролер | 193 |
| 6. | Спортның кышкы төрләре буенча контролер | 205 |
| 7. | Спорт судларына хезмәт күрсәтү буенча эш | 189 |
| 8. | Техник-моторист | 217 |
| 9. | Техник, моторист-коткаручы | 217 |
| 10. | Ретрак йөртүче (снегоход) | 193 |
| 11. | Водолаз | 217 |
| 12. | Телефонистлар | 193 |
| 13. | Оператор | 217 |
| 14. | Спорт чараларына хезмәт күрсәтү буенча эш | 189 |
| 15. | Ярдәмче эшче | 188 |
| 16. | Рәссам | 256 |
| 17. | Видеотехникага хезмәт күрсәтү буенча инженер | 275 |
| 18. | Машинист хатын-кыз | 189 |
| 19. | Аккомпаниячe | 240 |
| 20. | Ветеринария табибы | 275 |
| 21. | Ат карауычы | 187 |
| 22. | Механик | 217 |
| 23. | Табиб | 312 |
| 24. | Шәфкать туташы | 241 |
| 25. | Күзәтүче, махсус корреспондент, матбугат секретаре | 275 |

искәрмә:

Гамәлдәге хезмәт законнары нигезендә ял һәм бәйрәм көннәрендә эшләгән өчен түләү күләме ике тапкыр арта»;

карарның 9 нчы кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Спортчыларны, тренерларны һәм физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларында башка катнашучыларны яшәү белән тәэмин итүгә чыгымнар нормасы»

| № п/п | Яшәү өчен торак пунктларның категорияләре исеме | Бер кешегә бәя, сум |
|---|---|---|
| 1 | Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи шәһәрләре | 1120 кадәр |
| 2 | Россия Федерациясе субъектларының административ үзәкләре;<br>Төньяк территориясенә кертелгән шәһәрләр, торак пунктлар | 910-1120 |
| 3 | Россия Федерациясе территориясендә башка шәһәрләр һәм торак пунктлар | 670-850 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Физик культура, спорт һәм туризм идарәсе ведомствосы буенча тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән башкарыла дип билгеләргә.

3. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — М.Н. Гирфанов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ